**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«23» июнь 2021 ел** **№ 199**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясына, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына таянып, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә

2. Ачык тыңлауларны үткәрү инициаторы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башлыгы.

3. Билгеләргә:

үткәрү вакыты: 2021 елның 29 июненнән 2021 елның 30 июленә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

үткәрү урыны: Азнакай районы, Вахитов авыл җирлеге, Җиңү бистәсе, Үзәк ур., 30;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Азнакай шәһәре, ур.М. Солтангалиева, 24 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге Азнакай районы ; , Вахитов авыл җирлеге, Җиңү бистәсе, Үзәк ур., 30 Вахитов авыл җирлеге башкарма комитеты Азнакай муниципаль районы.

4. Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башкарма комитетына:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча халык алдында тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең генераль планы проекты материалларын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәгдәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

5. Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең генераль планы проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен әзерләү буенча эш төркем составын кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М. З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы
башлыгы карарына кушымта
« 23»__06___ 2021 №__199

Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү турында фикер алышу буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А. Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Әюпова Р. Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Бухарова И. Б. | Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Н.Г. | Азнакай район Советының җирлекләр белән эшләү секторы мөдире |
| Шәрәфетдинова С. Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |